| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>СОВЕТ ЕВЛАШТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>, Республика Татарстан, Сабинский район,<br>с.Евлаштау, ул. Ш.Бариева, д.23<br>тел. (84362) 46-8-49 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯВЛАШТАУ АВЫ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ<br><br>, Татарстан Республикасы, Саба районы,<br>Явлаштау авылы, Ш.Бариев урам 23 йорт<br>тел. (84362) 46-8-49 |

e-mail: Evlash.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
03.02.2020

КАРАР
№ 3

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 августында 17 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бердәм башкарма орган буларак катнашу яисә аларның коллегиаль органнары составына керү өчен рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Явлаштау авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 августында 17 номерлы карары белән кабул ителгән "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бердәм башкарма орган буларак катнашу яисә аларның коллегиаль органнары составына керү өчен рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1 пунктында «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы, " сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәренде http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге рәсми сайтында

http://saby.tatarstan.ru/rus/evlashtay. адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә калдырам.

Явлаштау авыл
җирлеге башлыгы Р.Х.Нуриев